СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 23 от 03.11.2020
на № _от ________

# КАРАР

“Саба урман хуҗалыгы” ачык акционерлык
җәмгыятен бетерү турында

Хуҗалык эшчәнлеге булмауга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. “Саба урман хуҗалыгы” ачык акционерлык җәмгыятен бетерергә.
2. Ликвидация комиссиясен түбәндәге составта төзергә:

| | |
|---|---|
| А.М. Галиуллин, | Саба муниципаль районынын Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе, ликвидация комиссиясе рәисе; |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| М.Т. Гарәфетдинова, | “Саба өйрәнү-сынау урман хуҗалыгы” ДБУнен баш хисапчысы урынбасары; |
| А.И. Миникәев, | Саба муниципаль районы Советыныц юридик бүлеге начальнигы; |
| Ш.Ә. Сөнгәтов, | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча); |

3. Ликвидация комиссиясенә 3 ай эчендә “Саба урман хуҗалыгы” ачык акционерлык җәмгыятен (алга таба-җәмгыять) бетерү буенча эшне башкарырга, шулай ук:

– кредиторларны ачыклау һәм дебитор бурычларын алу чараларын күрергә, шулай ук кредиторларга Җәмгыятьне бетерү турында язмача хәбәр итәргә;

– Җәмгыятьне бетерү турында басманы “Дәүләт теркәве хәбәрләре” мәгълүмат бюллетенендә урнаштырырга;

– матбугатта бетерү турында хәбәр басылып чыккан көннән соң ике ай вакыт узгач, раслау өчен арадаш ликвидация балансын төзергә;

– кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң, Җәмгыятьнең ликвидацион балансын төзергә һәм аны раслауга тапшырырга;

– арадаш ликвидация балансын һәм ликвидация балансын юридик затларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы тиешле органга җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына, әлеге карарныц 1 пунктында каралган ликвидация чаралары тәмамланганнан соң, Җәмгыять мөлкәте һәм акчаларын муниципаль район казнасына кабул итүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны ликвидация комиссиясе рәисенә йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов